# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧИЯБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

2020 елның 21 сентябре № 6

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Чиябаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ номерлы Федераль законга( соңгы үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ номерлы Законына карата, Әлки районы прокуратурасының хокукый инициативасын өйрәнеп, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 85, 86 статьясы нигезендә Чиябаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2018 елның 11 октябрендәге 24 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын беренче укылышта 1 нче кушымта нигезендә хупларга.

2.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын махсус җиһазланган мәгълүмати стендларда һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http://pravo.tatarstan.ru/ порталында урнаштырып халыкка җиткерергә.

3.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карау буенча түбәндәге составта эшче төркем төзергә:

- Шәрипова Рәсинә Ринатовна -Чиябаш авыл җирлеге Советы депутаты;

- Хисмәтов Марсель Касымович -Чиябаш авыл җирлеге Советы депутаты;

- Зәйнуллин Мәсхүт Мансурович -Чиябаш авыл җирлеге Советы

депутаты;

4. «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча 2020 елның 15 октябрендә Чиябаш авыл җирлеге Советы бинасында җәмәгать тыңлаулары үткәрергә.

5. Эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге советы депутатлары һәм гражданнар тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Чиябаш авыл җирлеге Советы каравына чыгарырга.

6.«Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты үтәлешен контрольдә тотуны, карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карауны эшче төркемгә йөкләргә.

Совет Рәисе, Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы Чиябаш
авыл җирлеге Башлыгы: И.З.Сәмигуллин

Советының карарына
Чиябаш авыл җирлеге
Советының 2020 елның 21 сентябрендәге 6 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чиябаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**6 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 16 пунктча өстәргә:**

«16) участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны хезмәткәр биләгән чорга торак урыны бирү.»;

**6 статьяның 1 пунктындагы 12 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«12) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру;»;

**47 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:**

« - участок уполномоченные вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны хезмәткәр биләгән чорга торак урыны бирү.»;

**47 статьяның 2 пунктындагы 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

« - җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне тормышка ашыру;»;

**2021 елның 1 гыйнварына кадәр 78 статьяның 3 пунктын һәм 83 статьяның 5 пунктың гамәлдә булуын туктатып торырга.**